**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№7334**
**15.11.2021**

2022 елга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең туризм-туган якны өйрәнү, экология-биология, хәрби-патриотик, социаль-педагогик, социаль-икътисадый, табигый-фәнни, техник һәм культурология юнәлешләрендә балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларының һәм балаларга өстәмә белем бирү буенча күп профильле мәгариф оешмаларының норматив чыгымнарын раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясы, «Мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 99 статьясы, Башкарма комитетның «Яр Чаллы шәһәренең туризм-туган якны өйрәнү, экология-биология, хәрби-патриотик, социаль-педагогик, социаль-икътисадый, табигый-фәнни, техник һәм культурология юнәлешләрендә балаларга өстәмә белем бирү мәгариф учреждениеләрен һәм балаларга өстәмә белем бирү буенча күп профильле мәгариф учреждениеләрен финанслау нормативларын исәпләү тәртибен раслау турында» 2020 елның 27 мартындагы 1540 номерлы карары нигезендә

К А Р А Р   Б И Р Ә М:

1. Расларга:

1) 2022 елга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең туризм-туган якны өйрәнү, экология-биология, хәрби-патриотик, социаль-педагогик, социаль-икътисадый, табигый-фәнни, техник һәм культурология юнәлешләрендә балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларында һәм балаларга өстәмә белем бирү буенча күп профильле мәгариф оешмаларында өстәмә белем бирү программаларын тормышка ашыруга норматив чыгымнарны кушымтада каралганча;

2) 2022 елга туризм-туган якны өйрәнү, экология-биология, хәрби-патриотик, социаль-педагогик, социаль-икътисадый, табигый-фәнни, техник һәм культурология юнәлешләрендә балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларында һәм балаларга өстәмә белем бирү буенча күп профильле мәгариф

оешмаларында өстәмә белем бирү программаларын тормышка ашыруга норматив чыгымнарга төзәтмә кертү коэффициентын 0,5 күләмендә.

2. Башкарма комитетның финанс идарәсенә тәэмин итәргә:

1) балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларын әлеге карарның 1 пунктында каралган балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларының норматив чыгымнарына туры китереп финанслауны;

2) гамәлдә булу вакыты дәвамында әлеге карарның 1 пунктында каралган балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларының норматив чыгымнарын, хезмәт законнарында һәм башка норматив хокукый актларда билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла торган балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт хакын индексацияләү белән бер үк вакытта яңадан тикшерүне.

3. Әлеге карар 2022 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

4. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгы С.Р. Мулюковага йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2021 елның 15 ноябрендәге
7334 номерлы карарына
кушымта

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең
туризм-туган якны өйрәнү, экология-биология, хәрби-патриотик, социаль-педагогик, социаль-икътисадый, табигый-фәнни, техник һәм культурология юнәлешләрендә балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларында һәм балаларга өстәмә белем бирү буенча күп профильле мәгариф оешмаларында өстәмә белем бирү программаларын тормышка ашыруга норматив чыгымнар

| Өстәмә белем бирү программасының юнәлеше | Территориаль дислокациясе | Норматив чыгымнар, елына бер укучыга сум | | |
|---|---|---|---|---|
| | | беренче уку елы | икенче уку елы | өченче һәм аннан соңгы уку еллары |
| Сәнгать-эстетика | шәһәр җирлеге | 5 569 | 10 314 | 12 376 |
| Физкультура-спорт | шәһәр җирлеге | 5 468 | 10 126 | 12 151 |
| Техник иҗат | шәһәр җирлеге | 5 873 | 10 876 | 13 051 |
| Туризм-туган якны өйрәнү | шәһәр җирлеге | 5 671 | 10 501 | 12 601 |
| Экология-биология | шәһәр җирлеге | 5 671 | 10 501 | 12 601 |
| Хәрби-патриотик | шәһәр җирлеге | 5 671 | 10 501 | 12 601 |
| Социаль-педагогик | шәһәр җирлеге | 5 266 | 9 751 | 11 702 |
| Социаль-икътисадый | шәһәр җирлеге | 5 266 | 9 751 | 11 702 |
| Табигый-фәнни | шәһәр җирлеге | 5 671 | 10 501 | 12 601 |

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы Н.И. Галиева